**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СЕМИОЗЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
420099, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Семиозерка, ул. Верхняя, 99А

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СЕМИОЗЕРКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
420099, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Семиозерка авылы, Верхняя ур., 99А

тел./факс 8(84365) 32-9-63, e-mail: 7Ozer.Vsg@tatar.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

**« 25 » февраля 2026 г.** **№ 42**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Семиозерка авыл җирлеге Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районы Семиозерка авыл җирлеге территориясендә адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»2021 елның 27 сентябрендәге 227 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Биектау районы прокуратурасының 30.12.2025 № 02-08-01-2025/Прдп415-25-20920014 протестын үтәү йөзеннән Биектау муниципаль районы Семиозерка авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ::

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Семиозерка авыл җирлеге Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районы Семиозерка авыл җирлеге территориясендә адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»2021 елның 27 сентябрендәге 227 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 бүлек 1.2 пунктының 10 абзацында «әлеге пунктта күрсәтелгән зат исеменнән» сүзләрен «гаризалы " сүзенә алмаштырырга»;

1.2. 2.3 бүлегенең 2.3.2 пунктында «берләштерелергә мөмкин» сүзләрен «берләштерелә»сүзенә алмаштырырга;

1.3. 2.4 бүлекнең 2.4.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы:

- гариза кәгазьдә бирелгән очракта-гариза кергән көннән алып 10 эш көненнән дә соңга калмыйча;

- электрон документ рәвешендә гариза биргән очракта-гариза кергән көннән алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча.

Муниципаль хезмәтне алдан кисәтү (проактив) режимда күрсәткән очракта- регламентның 1.6 пунктында күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткән көннән алып 3 эш көне.

Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы гариза теркәлгән көннән соң икенче көнгә исәпләнә башлый".

2. Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча әлеге карарны халыкка җиткерергә: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru.

Башкарма комитет җитәкчесе
Семиозерск авыл җирлеге Г.Т. Игизбаева